**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«21» октября 2020 № 389

**«2021 елга «Әтнә муниципаль районы» Гомуми белем бирү муниципаль берәмлекләренең норматив чыгымнарын раслау турында»**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитетының 2007 елның 11 декабрендәге 436 номерлы карары нигезендә КАРАР ЧЫГАРА:

1. 2021 елга түбәндәгеләрне расларга:

«Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар;

2. «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге финанс-бюджет палатасына, мәгариф оешмаларының түбәндә күрсәтелгән норматив чыгымнары нигезендә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

«2021 елга Татарстан Республикасында гомуми һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2020 елның 26 сентябрендәге 56-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә.

Әлеге карарның 1 пункты белән.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе урынбасары Ф.И. Гыймадиевка йөкләргә.

ТР Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы: М.Л.Халиков

Әтнә районы Башкарма комитетының 2020ел 21 октябрендә 389номерлы карары белән расланган

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

**Татарстан Республикасы «Әтнә муниципаль районы " муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмаларында һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тоту өчен»**

| Гомуми белем бирү оешмасы тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы Интернат | авыл җирлеге | 94213 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 143701 |